**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕКУЛЬГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422660, с. Большая Кульга ,
ул. Школьная , дом 11

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ОЛЫ КУЛЬГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422660, Олы Кульга авылы,
Мэктэп урамы, 11 нче йорт,

Тел.: (84361) 29202, факс: (84361) 29202, e-mail: Bklg.Rs@tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.05.2019 .Олы Кульга авылы №12

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар хисабына гамәлгә ашырылучы чыгымнар юнәлешләрен раслау турында

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру максатларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 апрелендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында” 143пи номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенең 3 пункты һәм Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Законының 15 маддәсе 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә алына торган башка бюджетара трансфертлар хисабына гамәлгә ашырылучы чыгымнар юнәлешен расларга.

2. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Кульга авыл җирлеге башлыгы Е.А.Терентьев